**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Алькеевский муниципальный район Совет Новоургагарского сельского поселения**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы Иске Үргәагар авыл җирлеге Советы**

Адрес: 422870, РТ, Алькеевский район с.Старые Ургагары , Г.Тукая, д.4
факс: 8 (84346) 73-7-76

Адресы: 422870, РТ, Әлки районы, Иске Үргәагар авылы, Г.Тукай ур, 4 й.
тел: 8 (84346) 73-7-76

**РЕШЕНИЕ** Иске Үргәагар авылы **КАРАР**

2025 нче елның 30нчы гыйнвары 101 №

2018 нче елның 14 нче декабрендәге
“Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәне раслау турында”гы
Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлегенең
29 нче номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

2023 нче елның 12 нче декабрендәге "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 594 нче Федераль законының 12 нче маддәсе, 2024 нче елның 8 нче августындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 232 нче номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2018 нче елның 14 нче декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында"гы 29 нче номерлы (2019 нчы елның 20 нче мартындагы 5 нче номерлы карары, 2020 нче елның 12 нче февралендәге 4 нче номерлы карары, 2020 нче елның 10 нчы июнендәге 10 нчы номерлы, 2021 нче елның 30 нчы июлендәге 21 нче номерлы, 2023 нче елның 9 нчы февралендәге 58 нчы номерлы карары, 2023 нче елның 7 нче сентябрендәге 64 нчы карары, 2024 нче елның 22 нче мартындагы 82 нчы номерлы карары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

4 маддәнең 4 пунктында", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына" сүзләрен төшереп калдырырга.;

6нчы маддәнең 4нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.";

13нче маддәне яңа редакциядә үзгәртергә:

"13нче маддә. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру»;

13нче маддәнең 7нче пунктында "(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 8нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 10нчы пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.

13нче маддәнең 11нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

14нче маддәнең 3нче пунктындагы 5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «5) белем һәм квалификация турында документ;»

30нчы маддәнең 2нче пунктындагы 2.5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5. муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыра һәм үткәрә;»

30нчы маддәнең 2нче пунктында түбәндәге эчтәлекле2.5.1 пунктча өстәргә.:

«2.5.1. дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвешне кертүне рәсмиләштерә;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегенең мәгълүмат тактасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Советы Рәисе,
Яңа Үргәагар авыл җирлеге Башлыгы — Ә.Ә.Рәхимҗанов